ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2024 п.г.т.Алексеевское № 528

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 25.12.2023 ел, № 622 «2024 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап торкан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 09.10.2024 № 04-08/13538 хатына таянып,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 25.12.2023 ел, № 622 «2024 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау хакында»;

- карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән торак урыннар

милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләменең иң чик индексын 12% күләмендә расларга».

2. Баш мөхәррир Е.Д. Ахманаевага әлеге карарны «Заря» (Таң) район газетасында бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**